**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«11» 12 2024 ел Яр Чаллы ш. № 5527

ТР Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 23 январендәге 175 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы К.Р. Нәҗмиев

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «11» 12 5527 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 ноябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак гомуми белем мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә
бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1. | «Тиздән мәктәпкә» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2. | «Укы әле» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3. | «Скорочтение» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы
«Теләнче Тамак гомуми белем мәктәбе»
МБГББУ директоры ______________ А.Р. Хәмидуллина

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт
күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ______________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак гомуми белем мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

**1. «Тиздән мәктәпкә»** - мәктәпкәчә яшьтәге балаларны яңа белем бирү шартларына яраклаштыруга һәм белем бирүнең бер баскычыннан икенчесенә уңайлы күчеш булдыруга юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга бирелә.

Балалар саны: 15.

Бинаның мәйданы: 53,4 кв.м.

**2. «Укы әле»** - рациональ уку күнекмәләрен үстерү, уку һәм мәгълүматны үзләштерү тизлеген арттыру өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән. Тамаша һәм ишетү хәтере, игътибар, фикерләү, күзаллау үсешенә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 7 яшьтән 10 яшькә кадәрге балаларга бирелә.

Укучылар саны: 10.

Бинаның мәйданы: 55,5 кв.м.

**3. «Скорочтение»** - рациональ уку күнекмәләрен үстерү, уку һәм мәгълүматны үзләштерү тизлеген арттыру өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән. Тамаша һәм ишетү хәтере, игътибар, фикерләү, күзаллау үсешенә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 11 яшьтән 12 яшькә кадәрге балаларга бирелә.

Укучылар саны: 10.

Бинаның мәйданы: 56,2 кв.м.

ТР Тукай муниципаль районы<br>«Теләнче Тамак гомуми белем мәктәбе»<br>МБГББУ директоры ____________ А.Р. Хәмидуллина